КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ

## КАРАР

2017 ел, 10 май

№ 268

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 22 гыйнвар, 22 нче; 2005 ел, 30 май, 239 нчы; 2006 ел, 2 октябрь, 490 нчы; 2007 ел, 6 апрель, 123 нче; 2008 ел, 8 сентябрь, 640 нчы; 2010 ел, 29 ноябрь, 956 нчы; 2011 ел, 21 июнь, 496 нчы; 2011 ел, 6 декабрь, 1001 нче; 2012 ел, 13 апрель, 304 нче; 2013 ел, 19 гыйнвар, 20 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 8 февраль, 80 нче; 2014 ел, 5 декабрь, 947 нче; 2015 ел, 15 апрель, 254 нче, 2015 ел, 1 декабрь, 911 нче, 2016 ел, 22 июнь, 425 нче; 2016 ел, 10 сентябрь, 625 нче; 2016 ел, 20 декабрь, 959 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 нче пунктның алтынчы – уникенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«төп белем бирү программалары буенча укучы ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затларга транспортта йөрүгә субсидияләр (алга таба – транспортта йөрүгә субсидия);

Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы исәбеннән эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча төп һөнәри белем бирү программалары һәм (яки) һөнәри әзерлек программалары буенча көндезге формада укыган ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затларга белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны тәмамлап чыкканда бер тапкыр бирелә торган акчалата пособие (алга таба – укуны тәмамлап чыкканда бер тапкыр бирелә торган пособие);

Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы исәбеннән эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча төп һөнәри белем бирү программалары һәм (яки) һөнәри әзерлек программалары буенча көндезге формада укыган ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затларга белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны тәмамлап чыкканда өс киемнәре, аяк киемнәре, йомшак инвентарь һәм җиһазлар сатып алу өчен бер тапкыр бирелә торган пособие (алга таба – укуны тәмамлап чыкканда өс киемнәре, аяк киемнәре, йомшак инвентарь һәм җиһазлар сатып алу өчен бер тапкыр бирелә торган пособие);

Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы исәбеннән төп һөнәри белем бирү программалары буенча көндезге формада укучы ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затларга уку әдәбияты һәм язу әсбаплары сатып алуга еллык пособие (алга таба – уку әдәбияты һәм язу әсбаплары сатып алуга еллык пособие);

Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы исәбеннән төп һөнәри белем бирү программалары буенча көндезге формада укучы ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затларга өс киемнәре, аяк киемнәре һәм йомшак инвентарь сатып алу өчен еллык пособие (алга таба – өс киемнәре, аяк киемнәре һәм йомшак инвентарь сатып алу өчен еллык пособие);

Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы исәбеннән төп һөнәри белем бирү программалары буенча көндезге формада укучы ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга айлык стипендия (алга таба – айлык стипендия);

Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы исәбеннән төп һөнәри белем бирү программалары буенча көндезге формада укучы ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-

ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затларга туклану өчен айлык поособие (алга таба – туклану өчен айлык пособие).»;

6 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Транспортта йөрүгә субсидия, укуны тәмамлап чыкканда бер тапкыр бирелә торган пособие, укуны тәмамлап чыкканда өс киемнәре, аяк киемнәре, йомшак инвентарь һәм җиһазлар сатып алу өчен бер тапкыр бирелә торган пособие, уку әдәбияты һәм язу әсбаплары сатып алуга еллык пособие, өс киемнәре, аяк киемнәре һәм йомшак инвентарь сатып алу өчен еллык пособие, айлык стипендия, туклану өчен айлык пособие билгеләү һәм түләү тәртибе

6.1. Транспортта йөрүгә субсидия төп белем бирү программалары буенча укучы ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затларга билгеләнә һәм түләнә.

6.2. Уку әдәбияты һәм язу әсбаплары сатып алуга еллык пособие, өс киемнәре, аяк киемнәре һәм йомшак инвентарь сатып алу өчен еллык пособие, туклану өчен айлык пособие Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы исәбеннән төп һөнәри белем бирү программалары буенча көндезге формада укучы ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затларга, шул исәптән аларга 23 яки аннан күбрәк яшь тулса билгеләнә һәм түләнә.

Өс киемнәре, аяк киемнәре һәм йомшак инвентарь сатып алу өчен еллык пособие, туклану өчен айлык пособие балаларны караган өчен опекунга (попечительга) акча түләнә торган гаиләләргә опекага (попечительлеккә) бирелгән ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга билгеләми һәм түләнми.

6.3. Укуны тәмамлап чыкканда бер тапкыр бирелә торган пособие, укуны тәмамлап чыкканда өс киемнәре, аяк киемнәре, йомшак инвентарь һәм җиһазлар сатып алу өчен бер тапкыр бирелә торган пособие Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы исәбеннән эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча төп һөнәри белем бирү программалары һәм (яки) һөнәри әзерлек программалары буенча көндезге формада укыган ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затларга, шул исәптән аларга 23 яки аннан күбрәк яшь тулса, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны тәмамлап чыкканда билгеләнә һәм түләнә.

6.4. Айлык стипендия Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы исәбеннән төп һөнәри белем бирү программалары буенча көндезге формада укучы ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затларга, шул исәптән аларга 23 яки аннан күбрәк яшь тулса, инвалид

балаларга, инвалидларга (алга таба – түләү алучылар) белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны тәмамлап чыкканда билгеләнә һәм түләнә.

6.5. Транспортта йөрүгә субсидия, укуны тәмамлап чыкканда бер тапкыр бирелә торган пособие, укуны тәмамлап чыкканда өс киемнәре, аяк киемнәре, йомшак инвентарь һәм җиһазлар сатып алу өчен бер тапкыр бирелә торган пособие, уку әдәбияты һәм язу әсбаплары сатып алуга еллык пособие, өс киемнәре, аяк киемнәре һәм йомшак инвентарь сатып алу өчен еллык пособие, айлык стипендия, туклану өчен айлык пособие алу өчен түләү алучылар, аларның законлы вәкилләре яисә алар ышанычнамә нигезендә вәкаләтләр биргән затлар (алга таба – гариза бирүчеләр) белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма урнашкан урын буенча яисә опекун (попечитель) яки түләү алучы яшәгән урын буенча Үзәк бүлегенә түбәндәгеләрне тапшыра:

субсидия, стипендия, пособие билгеләү турында гариза;

һөнәри белем бирү оешмасыннан һәм югары белем бирүче мәгариф оешмасыннан, белем бирү оешмасын тәмамлап чыгу вакытын күрсәтеп, укуны раслый торган белешмә; Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә урнашкан белем бирү оешмасыннан укуны раслый торган белешмә. Белешмә ел саен уку елы башында бирелә;

вәкаләтле зат мөрәҗәгать иткән очракта ышанычнамә күчермәсе.

Айлык стипендия алу өчен инвалид балалар һәм инвалидлар өстәмә рәвештә медицина-социаль экспертиза бюросы белешмәсенең күчермәсен тапшыра.

Уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затлар өстәмә рәвештә уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалтуны раслый торган документлар күчермәләрен тапшыра.

Документларның күчермәләре нотариус яки орган (документның төп нөсхәсен биргән оешма, учреждение) тарафыннан расланган булмаса, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлегенең белгече тарафыннан раслана.

Гариза бирүчеләр гариза белән мөрәҗәгать иткәндә шәхесләрен таныклый торган документларын күрсәтә, банкта ачылган шәхси счет реквизитларын бирә.

6.6. Үзәк бүлеге ведомствоара соратулар нигезендә, шул исәптән электрон формада, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, опека (попечительлек) билгеләү турында һәм опекага алынучыны карау өчен опекунга айлык акчалата түләү бирү вакытлары хакында мәгълүматлар, баланың Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмасында уку узуы турында мәгълүмат ала.

6.7. Әлеге Нигезләмәнең 6.5 нче пунктында күрсәтелгән түләүләрне алу максатларында, гариза бирүчеләр үз инициативалары буенча Үзәк бүлегенә бу Нигезләмәнең 6.6 нчы пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар булган документлар тапшырырга хокуклы.

6.8. Үзәк бүлеге барлык кирәкле документлар белән транспортта йөрүгә субсидия, укуны тәмамлап чыкканда бер тапкыр бирелә торган пособие, укуны тәмамлап чыкканда өс киемнәре, аяк киемнәре, йомшак инвентарь һәм җиһазлар сатып алу өчен бер тапкыр бирелә торган пособие, уку әдәбияты һәм язу әсбаплары сатып алуга еллык пособие, өс киемнәре, аяк киемнәре һәм йомшак инвентарь сатып алу өчен еллык пособие, айлык стипендия, туклану өчен айлык пособие билгеләү турындагы гаризаны теркәгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә аларны билгеләү турында яки аларны билгеләүдән баш тарту хакында карар

кабул итә һәм гариза бирүчегә кабул ителгән карар турында гаризада күрсәтелгән ысул буенча (хат, смс-хәбәр, электрон почта аша) хәбәр итә.

6.9. Транспортта йөрүгә субсидия, айлык стипендия, туклану өчен айлык пособие, әгәр гариза һәм кирәкле документлар белән мөрәҗәгать һөнәри белем бирү оешмасына яки югары белем бирү оешмасына укырга алынган көннән соң өч айдан да соңга калмыйча бирелсә, һөнәри белем бирү оешмасына яки югары белем бирүче мәгариф оешмасына укырга алынган вакыттан башлап билгеләнә, күрсәтелгән вакыт чыкканда – гариза һәм кирәкле документлар белән мөрәҗәгать иткән айдан билгеләнә.

Гомуми белем бирү оешмаларында укучы ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга транспортта йөрүгә субсидия гариза һәм кирәкле документлар белән мөрәҗәгать иткән айдан билгеләнә.

6.10. Укуны тәмамлап чыкканда бер тапкыр бирелә торган пособие, укуны тәмамлап чыкканда өс киемнәре, аяк киемнәре, йомшак инвентарь һәм җиһазлар сатып алу өчен бер тапкыр бирелә торган пособие укуны тәмамлаган көннән соң бер ай эчендә билгеләнә һәм бер тапкыр түләнә.

6.11. Уку әдәбияты һәм язу әсбаплары сатып алуга еллык пособие, өс киемнәре, аяк киемнәре һәм йомшак инвентарь сатып алу өчен еллык пособие уку елына бер тапкыр бирелә.

6.12. Уку елы дәверендә түләү алучыны караган өчен опекунга акча түләү туктатылган очракта өс киемнәре, аяк киемнәре һәм йомшак инвентарь сатып алу өчен еллык пособие, опекунга түләү бирү туктатылган айдан соң килә торган айдан башлап, уку елы тәмамланырга калган айлар санына тәңгәл күләмдә түләү алучыга түләнә.

6.13. Пособиеләр, стипендияләр, субсидияләр бирү түләү алучының үлеменә, гомуми белем бирү оешмасыннан, һөнәри белем бирү оешмасыннан яки югары белем бирүче мәгариф оешмасыннан чыгуына бәйле туктатыла.

6.14. Пособиеләр, субсидияләр, стипендияләр алуга хокукы булган түләү алучы укудан чыгарылса, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар җитәкчеләре боерык чыккан көннән соң өч эш көне эчендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма урнашкан урын буенча Үзәк бүлегенә түләү алучыны укудан чыгару турындагы боерыкның өземтәсен тапшырырга тиеш.

6.15. Транспортта йөрүгә субсидия, уку әдәбияты һәм язу әсбаплары сатып алуга еллык пособие, өс киемнәре, аяк киемнәре һәм йомшак инвентарь сатып алу өчен еллык пособие, туклану өчен айлык пособие, укуны тәмамлап чыкканда бер тапкыр бирелә торган пособие, укуны тәмамлап чыкканда өс киемнәре, аяк киемнәре, йомшак инвентарь һәм җиһазлар сатып алу өчен бер тапкыр бирелә торган пособие, стипендия билгеләүдән баш тарту өчен нигез булып әлеге Нигезләмәнең 6.5 нче пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау тора.»;

10.2 нче пунктның икенче абзацын төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\268.doc